СОВЕТ ШУБАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ**

«14» май 2025ел.

**КАРАР**

№135

**Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Шубан авыл җирлеге башлыгының, Шубан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең хезмәтенә түләү тәртибе турында»гы 2018 елның 25 декабрендәге 91нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**
**(2023 елның 14 марты 69нчы номерлы, 2024 елның 17 июле 105 нче номерлы, 2024 елның 28нче ноябре 116нчы номерлы үзгәрешләре белән)**

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары, муниципаль хезмәткәрләрнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 14 нче апреле 228 нче номерлы карары, «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы җирле үзидарә органнарының даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы вазыйфаи затларына, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең контроль-хисап палатасы рәисенә, муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәре, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе күләмнәре турында» Татарстан Республикасы Балтач район Советының 2018 елның 28 апрелендәге 127 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Советының 2025 елның 30 нчы апреле 315 нче номерлы карары һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Уставы нигезендә Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге Советы карар итте:

1.«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге башлыгының, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге муниципаль хезмәткәренең (алга таба - Карар) хезмәтенә түләү тәртибе турында» 2018 елның 18 декабрендәге 91 нче номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 2 пунктындагы «13990» санын «15389» санына алмаштырырга;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шубан авыл җирлеге башлыгы хезмәтенә түләү Тәртибенең ( 1нче кушымта) 1 пунктында «19173» санын «21091» санына алмаштырырга.

2. Әлеге карар 01.01.2025 елында үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми

порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шубан авыл җирлеге башлыгы С.З.Васильева.